ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТҮКЕ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

СОВЕТ
ТЮКОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

423732, Туке авылы, Ленин урамы
61/2 нче йорт. Тел/факс 5-70-42

423732, село Тюково, ул.Ленина,
дом 61/2. тел/факс 5-70-42

№ 2 14 ноябрь 2019 ел

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы
Түке авыл җирлегендә халык җыены

**Карары**

- Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Түке авыл җирлеге Зөбәер авылы территориясендә бер тапкыр алына торган түләүләр кертү турында:

2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы» нигезендә

1. Түке авыл җирлеге Зөбәер авылы территориясендә сугыш хәрәкәтләрендә катнашучылардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан кала яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә - 500(биш йөз) сум күләмендә түләү кертергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:
   Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү:
   - суүткәргеч челтәрен ремонтлау, карап тоту һәм рәсмиләштерү ; ;
   - Чишмәләр территориясен төзекләндерү;
   Җирлек чикләрендә төзекләндерү эшләрен оештыру:
   - социаль объектлар территориясен төзекләндерү;
   Юл эшчәнлеге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата:
   - агымдагы ремонт, кардан чистарту, ел дәвамында юлларны тигезләү;

Тавыш бирү нәтиҗәләре:» Әйе " - **114 кеше.**
"Каршы" - **0 кеше.**

Халык җыенының рәисе Р. М. Нуртдинов

Халык җыенынң сәркатибе З. С. Галимова

Түке авыл җирлеге башлыгы Р. М. Нуртдинов